**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

**егерменче дүртенче утырыш**

**21 октябрь 2022ел** **№ 98** **Шәтке авылы**

**Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»2018 елның 28 августындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары,«Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Билгеләргә:

1.1. 2020 елның 1 октябреннән 2022 елның 30 сентябренә кадәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 11498,0 сум тәшкил итә.

1.2. 2020 елның 1 октябреннән 2022 елның 30 сентябренә кадәр муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме 15759,0 сум тәшкил итә.

1.3. 2020 елның 1 октябреннән 2022 елның 30 сентябренә кадәр муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарының айлык акчалата бүләкләү күләме 11499,0 сум тәшкил итә.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Теләче муниципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Кадыйров

СОВЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ